| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ГЛАВА СТАРОЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ** |
| 423004, с. Старые Челны, ул. Ленина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73 | | 423004, Иске Чаллы авылы, Ленина ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73 |

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Чаллы ав. **КАРАР**

**«29» март 2024 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 9 апрелендә 11 сәгать 00 минутка Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында Гагарин, Яшьләр һәм Үзәк, Полевая урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә

2. 2024 елның 9 апрелендә 12 сәгать 00 минутка Түбән Чаллы авылы, Ленин урамы, 3А йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында Болын һәм Елга арьягы, Чапаев, Ленин һәм Мәктәп тыкрыгы урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Түбән Чаллы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне распарга:

«Сез элек расланган гражданнар җыенында чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 12 октябрендәге 5 номерлы карары,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 12.10.2023 ел, № 6 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

«РИЗА» «КАРШЫ» ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Түбән Чаллы авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров